# Хатлар язу

kausar

# ХАТ ТӨРЛӘРЕ

- Шәхси  хатлар - официальные письма
- Рәсми  хатлар - личные письма
- Мәхәббәт хатлары - любовные письма
- Дуслык хатлары - дружеские письма
- Көтеп алынган хатлар - долгожданные письма
- Җавап хаты - ответное письмо
- Фронт хатлары - фронтовые письма
- Электрон хатлар - электронные письма





Кайбер татар язучылары әдәби әсәрләрен хат рәвешендә язганнар.

Һ. Такташның “Киләчәккә хатлар”

Г. Кутуйның“Тапшырылмаган хатлар”

,Р.Асылбаевның “Болытка хат”

Ф.Кәримнең”Пионерка Гөлчәчәккә хат”

әсәрләре әнә шундыйлар.



**Кайбер рус язучылары да әсәрләрен хат рәвешендә язганнар.**

**А.С. Пушкин “Капитанская дочка”**

**“Евгений Онегин”**

**С. Есенин. “ Письмо к матери”**

**“Письмо от матери”**

**“Письмо деду”**

**“Письмо к сестре”**

**“Письмо к женщине”**

# 1941 ФРОНТ ХАТЛАРЫ 1945

Солдат хатлары... Кыска гына ял вакытында солдат окопта яки блиндажда, кәгазен калай савыт төбенә яки тез башына куеп, хат яза. Дошманга булган ачы нәфрәте дә, туган илгә булган көчле мәхәббәте дә, сугыш авырлыгы, яраларының сызлавы, иптәшләренең һәлак булу кайгысы-барысы да шушы хатка сыеп беткән.

Солдат язылып беткән хатын бик пөхтәләп, өчпочмаклап төрә, адресын яза һәм кыр почтасына илтеп сала. Шулай ул, иң изге теләкләрен әйтеп, гаиләсенә сәлам хаты җибәрә.

Ә хат, канатлы кош кебек, ерак-еракка "оча". Ул солдатларның ялкынлы сүзләрен туган иленә, гаиләсенә, якын кешесенә җиткерә.





# E-MAIL (ЭЛЕКТРОН АДРЕС)


**Соңгы 10 елда хат төшенчәсе традицион мәгънәсен бик күпкә үзгәртте. Гади конверт, открыткаларга алмашка электрон почта, смс хәбәрләр килде. Алар ярдәмендә без шушы минут, секундта ук әллә ничә чакрымнар аерган якыннарга сәлам юллый алабыз.**

**Бүген Россиядә тәүлегенә 2 млн. данә конвертка салынган хат ташылса, электрон почта хезмәтләре аша алынган хат-открыткалар берничә меңгә күбрәк. Әмма әлеге хәбәрләр берничек тә каләм белән кулдан язган сүзләрне алыштыра алмый шул. Аларда җылылык та, нур да юк.**





# ГИА ГА ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ
# “С” БИРЕМЕ



3 нче бүлек

**С1. Сез татар дустыгыздан хат алдыгыз. Шушы сорауларга җавап биреп, аңа хат языгыз. Язма эшегез 70-80 сүздән торырга тиеш.**

> *... Кичә мәктәбебездә Габдулла Тукайга багышланган Шигърият бәйрәме булды. Бәйрәмдә танылган татар шагыйрьләре, укытучылар, укучылар катнашты.*
>
> *1) Синең мәктәбеңдә татар шагыйрьләренә багышланган бәйрәмнәр буламы? 2) Син Муса Җәлилнең иҗаты белән танышмы? 3) Яраткан шагыйрең кем, аның иҗаты сиңа ни өчен ошый?*

26

# ДУСТЫМА ХАТ

Исәнме, дустым Алия! Күп сәлам белән синә дустың Надя хат яза. Әти-әниеңә, әбиеңә, дусларыңа миннән күп сәлам тапшыр. Алия, мин синең хатыңны алдым, бик зур рәхмәт. Син имтиханнарга ничек әзерләнү турында сорагансың. Дустым, без быел имтиханнарны яңа формада бирәчәкбез. Имтиханнарны яхшы тапшыру өчен, тырышып әзерләнергә кирәк. Мин дүрт фәннән имтихан тапшырыргателим: математикадан, рус теленнән, татар теленнән һәм инглиз теленнән. Дәресләрдә укытучыларны игътибар белән тыңлыйм. Алия, үзеңнең хәлләрең ничек, авырмыйсыңмы? Мәктәптә, нинди яңалыклар бар? Ял көннәрен ничек үткәрәсең? Барысы турында да яз, мин синнән хат көтәм.



Сагынып, дустың Надя
9а класс Маркина Надя


LG

Сәлам Яшел Үзәннән!

Исәнме дустым Алсу!

Сиңа хат яза дустың Лера.

Синең хат алдым, бик зур рәхмәт. Дустым, хәлләрең ничек? Авырмыйсыңмы? Мәктәбегездә яңалыклар бармы?

Минем хәлләрем яхшы. Авырмыйм. Әти-әнием, туганнарым да исән-сау. Алардан да сиңа күп сәламнәр.

Авылда кышкы каникул вакытында бик күңелле. Таудан чана һәм чаңгы, мәктәп ишегалдындагы шугалакта тимераякта шуабыз. Әти-әнигә кар көрәргә дә булышам.

Алсу, сиңа укуыңда уңышлар телим. Авырма. Әти-әниеңә, дусларыңа минем сәлам әйт. Безгә кил. Миңа хат яз.

Саубул! Сиңа уңышлар телим дустың Лера.

2017нче елның 15нче гыйнвар.



# Мультфильм

# Аудио язма

# Тема буенча хат язу.

# Туган як табигате.

**Туган ягыңның табигате нинди? Сезнең якларда нәрсәләр бар? Син табигатьтә булырга яратасыңмы?**

# Туган көн

**Синең туган көнең кайчан? Син бу көнне ничек бәйрәм итәсең? Сиңа тагын нинди бәйрәмнәр ошый?**

**Хатлар, хатлар... Якын кешеңнең һәр хәрефе, һәр иҗеге кадерле. Хатлар - йөрәк тарихы. Күпме серләр саклый алар. Яралы җаннарга шифа, тулган күңелләргә дәва – ул хатлар. Ана хатлары... Бала хатлары... Кайгылы хатлар, борчулы хатлар, җавапсыз хатлар да бихисап. Хатларның төп мәгънәсе йөрәкләрне җылытуда бит... Әйдәгез күңел җылыбызны бер-беребезгә хатлар аша җиткерик. Телевизор карау, компьютерда уйнау вакытын киметеп, кулыбызга ак бит алып, якын кешеләребезгә хатлар юллыйк.**